ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.06.2021 г. Заинск № 327

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне аныклау турында» 2018 елның 19 мартындагы 439 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Зәй муниципаль районында белем бирү системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне аныклау турында» 2018 елның 19 мартындагы 439 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган (Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 декабрендәге 627 номерлы, 2020 елның 02 декабрендәге 551 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне аныклау турында нигезләмәнең 3.27 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль дәүләт мәгариф стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф стандартлары һәм мөстәкыйль билгеләнә торган таләпләр турында (алар булганда);»;

1.2. 11 абзацта «әзерлек юнәлешенә» дигән сүзләрдән соң «, фәнни белгечлек» дигән сүзләрне өстәргә;

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Л.Р. Печина
3-27-42